**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ 06.09.2024 № ПР-161 № ______

"Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе тарафыннан "Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге бюджетына салынган административ штрафлар түләү бурычын түләтүгә өметсез дип тану һәм исәптән чыгару турында карарлар кабул итү тәртибен раслау хакында" Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 27 августындагы ПР-205 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. "Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе тарафыннан "Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге бюджетына салынган административ штрафлар түләү бурычын түләтүгә өметсез дип тану һәм исәптән чыгару турында карарлар кабул итү тәртибен раслау хакында" 2018 елның 27 августындагы ПР-205 номерлы карарына (үзгәрешләр белән 2020 елның 07 августындагы № ПР-150) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. II бүлекнең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2.1. Бурыч түләтүгә өметсез дип танылa һәм түбәндәге очракларда исемлектән чыгарылырга тиеш:
а) административ штраф түләүче физик затның вафат булуы яисә аны Россия Федерациясенең гражданлык - процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан ителүе;
б) "бөлгенлек (банкротлык) турында" 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданның, индивидуаль эшкуарның банкротлык процедурасын тәмамлау-бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә, аны түләү бурычын үтәүдән ул күрсәтелгән Федераль закон нигезендә азат ителгән;
в) оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яисә) аны гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләп бетерү мөмкин булмау сәбәпле бюджетка түләүләр буенча юкка чыгарылмаган бурыч өлешендә бюджетка түләүләр түләүче оешма юкка чыгарылганда;

г) җәзага хөкем ителгәннәргә карата амнистия яисә ярлыкау турындагы актларны штраф рәвешендә куллану яисә суд тарафыннан карар кабул итү, шуның нигезендә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалта, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә;
«Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кайтарганда, күләме банкротлык турындагы эш буенча производство кузгату өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән бурычлар күләменнән артмаган бурыч барлыкка килү датасыннан биш елдан артык вакыт үтсә, суд приставы-башкаручы тарафыннан башкарма документны кире кайтару турында карар чыгару;
е) банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек средстволар булмау сәбәпле, бурычлыны банкрот дип тану яисә банкротлык турындагы эш буенча эшне туктату турындагы гаризаны суд тарафыннан кире кайтару турында акт кабул ителү;
ж) теркәүче орган карары буенча юридик затны юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру һәм "Башкару эшчәнлеге турында" 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтаруга бәйле рәвештә башкару эшен тәмамлау турында суд приставы-башкаручы тарафыннан әлек чыгарылган карарның булуы, - оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда аны гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан түләп бетерү мөмкин булмау сәбәпле бюджетка түләүләр буенча түләнмәгән бурыч өлешендә. Теркәүче органның "Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында" 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә юридик затны юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турындагы карары гамәлгә яраксыз дип танылган очракта, элек әлеге пунктча нигезендә түләтүгә өметсез дип танылган бюджетка түләүләр буенча бурыч бюджет (бухгалтерлык) хисабында.»
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җапаплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.А.Ильясов